ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» апреля 2026 ел № 101

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты карамагындагы муниципаль учреждениеләрдә хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 02 июнендәге 170 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты ведомствосындагы муниципаль учреждениеләрдә хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство тикшереп торуы турындагы нигезләмәгә 3К номерлы кушымтаның 4 пунктындагы б пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«б) планнан тыш күчмә тикшерү уздырылган очракта: тикшерелә торган затка ачыкланган хокук бозуны бетерү турында элек бирелгән, канәгатьләндерү срогы чыккан күрсәтмә реквизитлары; вәкаләтле органга кергән гражданнарның, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары реквизитлары; вәкаләтле орган җитәкчесенең Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Башлыгы (рәисе), Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләре белән; законнарның үтәлешенә ведомство күзәтчелеге кысаларында планнан тыш тикшерү уздыру турында прокурор таләбе реквизитлары һәм таләпкә беркетелгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр реквизитлары ».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**